РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» ноябрь 2021 ел г. Альметьевск № 1673

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының кайбер
карарларының үз көчләрен югалтуын
тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалтуын таныргa:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2012 елның 22 июнендәге 2221 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 11 июлендәге 2859 номерлы;

«Объектны урнаштыру урынын алдан килештерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2015 елның 9 февралендәге 231 номерлы;

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән өч ел дәвамында тиешенчә файдаланганда, җир кишәрлеген арендаторга милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 10 февралендәге 240 номерлы;

«Дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген социаль ипотека системасында торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 13 февралендәге 286 номерлы;

«Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт

Зак. № 305-2000

күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 12 июлендәге 1528 номерлы.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU ) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ